**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ УЛЬЯНОВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**УЛЬЯНОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

Центральная ул., 44 дом, Ульяновка село, 423115 тел./факс+7(84396) 2-33-16/2-33-17; email: Ul.Cmn2@tatar.ru Үзәк урамы, 44 йорты, Ульяновка авылы, 423115

**16 декабрь 2019 ел** **№ 130**

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы**
**Ульяновка авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Ульяновка авыл җирлеге Советының
2013 елның 7 ноябрендәге 59 номерлы
«Җир салымы турында» карарына
үзгәрешләр кертү хакында.

Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ульяновка авыл җирлеге Советы **КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ульяновка авыл җирлеге Советының 2019 елның 31 октябрендәге 124 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ульяновка авыл җирлеге Советының 2013 елның 7 ноябрендәге 59 номерлы «Җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында» карары үз көчен югалткан дип таныргa.

2. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ульяновка авыл җирлеге Советының 2013 елның 7 ноябрендәге 59 номерлы «Җир салымы турында» карарына (авыл җирлеге Советының 2014 елның 14 ноябрендәге 76 номерлы, 2018 елның 12 мартындагы 72 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 статьяда:

- 1 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә: « 1) 0,3% авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә яисә торак пунктларда авыл хуҗалыгы куллануы зоналары составында булган һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен кулланыла торган җирләргә карата;

- 2 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә: «2) 0,3% торак фонд һәм торак-коммуналь комплексның инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына кагылмаган объектка туры килә торган

җир кишәрлегенә хокуктагы өлештән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата (эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш);

- 4 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә: «4) 0,15% шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) эшмәкәрлек эшчәнлегендә файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә, шулай ук «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата»;

- 5 пунктны төшереп калдырырга.

- 6 пунктны 5 пункт дип санарга.

2. Әлеге карарның 2 пунктындагы 2.1 пунктчасының 2-4 абзацы нигезләмәләре 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә, әлеге карарның 2 пунктындагы 2.1 пунктчасының 5 абзацы 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, ләкин рәсми басылып чыккан көннән бер ай үткәннән соң.

3. Әлеге карарны «Безнең Чирмешән» («Наш Черемшан») район газетасының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмати рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуда җаваплылыкны үз өстемә алам.

ТР Чирмешән муниципаль районы
Ульяновка авыл җирлеге
Башлыгы, Совет рәисе Шәмсетдинов С.З.